Чыганак: **Хәйруллин, Х.Ф. Язучы һәм тормыш. Әдәбият теориясе, әдәби хәрәкәт мәсьәләләре.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1979.- 288 б.**

# Әхмәт Ерикәй шигырьләре

Әхмәт Ерикәй — халык арасында популяр шагыйрьләрнең берсе. Аның үзенчәлекле поэтик тавышы, иҗат йөзе бар, аның иҗат характеры шактый ачык билгеләнгән. Халык арасында ул үзен бигрәк тә җыр остасы итеп танытты. Аның «Комсомолка Гөлсара», «Кәккүк», «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Сандугач» һәм башка бик күп җырлары халык арасында киң таралды. Ерикәйнең кайбер җырларын киң масса, бигрәк тә яшьләр үз җырлары итеп җырлый һәм аерым өлешләрен үстерә, үзгәртә, киңәйтә бара, ә ул җырларның авторы булуын белми дә. Бу бер дә очраклы түгел. Бу факт Әхмәт Ерикәй җырларының халыкчан булуын, аның киң масса хисләрен, уйларын, мәхәббәтен тирәнтен аңлый һәм җырга «сала» белүен ачык күрсәтеп тора. Ерикәйнең әнә шундый җырлары, композиторларның күңелгә дәрт, ләззәт бирүчән матур көйләре белән берлектә, халык тарафыннан бик хаклы рәвештә хөрмәтләнәләр.

Әхмәт Ерикәй иҗатының үзенчәлеге, талантының көче җыр жанрында ачылды дидек. Шулай да аның иҗатын бер жанр белән генә чикләү дөрес булмас иде. Ул поэзиянең башка жанрларында да уңышлы әсәрләр тудырды. Ватан сугышы чорында аның иҗаты тагын да тирәнәя һәм киңәя төште. Моңа аның төрле җыентыклары, шул җөмләдән «Халкыма» (1945) җыентыгы яхшы мисал була ала. Ә. Ерикәйнең бөтен иҗаты яки башка җыентыклары турында җәелеп китмичә, әнә шул җыентыгына күз ташлыйк.

«Халкыма» — эчтәлеге ягыннан да, шигырь төрләре буенча да бай җыентык. Без анда ялкынлы публицистик рухтагы һәм шагыйрь өчен программа төсен алган шигырьләрне дә, сугышчан җырларны да, элегия, романска тартым булган лирик җыр һәм шигырьләрне дә очратабыз һәм канәгатьләнү белән укыйбыз.

Җыентыкның эчтәлеген, рухын бер нәрсә билгели, ул — шагыйрьнең патриотлыгы, героик совет халкының дошманны тиздән тар-мар итеп җиңүенә ышану тойгысы һәм халыкны көрәшкә өндәү. 1941 елда язылган «Ил чакыра», «Шаула, Москва», «Чебиләрне көзен саныйлар», «Ант итәбез» һ. б. публицистик рухтагы шигырьләрдә автор совет халкының үзенең сөекле Ватанын сакларга күтәрелүе, бердәмлеге турында җырлый. Ерикәй бик гади итеп, мәгънәле һәм хиссиятле шигырь юлларын көчле ярсу, омтылу белән яза:

Безнең илебез туды ут эчендә,
Безнең илебез туды үлмәскә,
Безнең Ватаныбыз әмер бирде:
Бер адым да артка чикмәскә!

Болыннарны ярып кояш чыгар,
Ул балкытыр ямьле җир йөзен;
Без бирмәбез, юк, без сүндермәбез
Октябрьның якты йолдызын!

*(«Ант итәбез».)*

Ә. Ерикәйнең «Халкыма» дип исемләнгән бу җыентыгында баштан ахырынача көчле патриотлык хисе, туган илебез, халкыбыз турында уйлану, борчылу яши.

Патриотик хис — абстракция түгел, «һавага корылган алтын сарай» түгел ул, бик конкрет, нигезле, канлы һәм җанлы хис. Ул чын шагыйрьдә гомуми декларация төсендә генә кала алмый, конкрет тормыш фактларына, тормыш күренешләренә мөнәсәбәттә чагыла. Ә. Ерикәй шигырьләрендә дә шундый конкретлык, үзенчәлекле поэтик мөнәсәбәт бар. Шагыйрь:

Ил димен мин, ил дигәнем —
Ул туып-үскән җирем;
Ул минем алтын кибәнем,
Ул дөнья көткән җирем.
Ул минем урман, кырларым,
Ул минем бакчаларым.
Ул минем гүзәл җырларым,

Ул борын төрткән җирем.
Ул минем халкым, ватаным,
Ул минем атам-анам.
Ул минем сөйгән дусларым,
Ул гомер иткән җирем.
...Тик илнең яшәве генә —
Данлы яшәвем минем.

*(«Ил».)*

Туган ил турындагы фикерен берникадәр гомуми, декларатив төстәрәк әйтү белән бергә, «Шаула, Москва», «Бу йортларда мин торам», «Тукайга», «Идел», «Синең хатларың», «Землянкада» һәм башка шуның кебек шигырьләрне язып, патриотик хисне конкрет поэтик телгә күчерә һәм җанлы образларын тудыра.

Совет кешеләренең шәхси тормышы да, гаилә, мәхәббәте дә ил язмышы белән тыгыз бәйләнгән. Моны шагыйрь «Хат яз миңа», «Синең хатларың» һ. б. лирик шигырьләрендә бик матур әйтә. Фронттан совет сугышчысы сөйгән кешесенә җылы һәм бик мәгънәле сүзләр яза:

Нур шикелле җылы хатларыңнан
Яшәү энҗеләрен өзәм мин,
Туган илнең бөек кайгыртуын
Синең хатларыңда сизәм мин.
Синең хатың, синең мәхәббәтең
Сугыш уты аша үтәрлек.
Сүрелмәслек изге сөю өчен
Яуга каршы кылыч күтәрдек.

*(«Синең хатларың».)*

Бер караганда, бик гади сүзләр генә болар, анда әллә нинди тантаналы, бизәкле сүзләр дә юк, ә шулай да бу юлларда тирән мәгънә һәм кешенең эчке сере, кичереше бар, шагыйрь монда күпчелек өчен уртак солдат моңын, хисен аңлый һәм бирә белгән.

Ә. Ерикәйнең лирикасы бүлмәгә бикләнгән, сентименталь лирика түгел, ә сугыш көндәлекләрен, совет кешеләренең, сугышчыларының уйларын һәм кичерешләрен чагылдырган сугыш лирикасы. Шундый лирик шигырьләрдән аеруча уңышлы эшләнгәннәре итеп «1943 нче ел» бүлегенә кергән шигырьләрен исәпләргә кирәк. Мәсәлән: «Җирне каплап моңсу болыт чыга», «Землянкада», «Утыр, дускай», «Ян, йолдызым», «Хат

яз миңа», «Синең хатларың» һ. б. Болар янына тагын 1944 елда язылган «Халкыма», «Ана», «Зәңгәр яулык», «Аккаен», «Шинель», «Җырчы кыз», «Күтәрик бокалларны» кебек уңышлы шигырь һәм җырларын өстәргә кирәк.

Бу шигырьләр Ә. Ерикәйнең нечкә лирик шагыйрь булуын күрсәтәләр һәм алар аның лирикасы үзенчәлекле конкрет төс алып, көчәеп, үсә һәм тирәнәя баруы турында сөйлиләр.

Менә «Землянкада» шигыре. Кечкенә генә бу шигырьдә әллә никадәр моң, уйлану. Бер карaганда, бик гади хәл: совет сугышчылары «дымлы землянкада бәрәңгене көлдә пешереп» утыралар, туган җирләрен, дус-ишләрен сагыналар, үткәннәрне искә төшерәләр. Шул ук вакытта аларда дошманга үч, ачу уты януын сизәсең, аларның «йөрәк өзгеч авыр минутларны» гомердә дә онытмаячакларына ышанасың һәм аларга кушыласың.

«Землянкада» шигыренә «Утыр, дускай» шигыре бик якын тора. Икесендә дә совет сугышчысының эчке кичерешләре йөрәккә үтемле лирик юлларда бирелгән. «Утыр, дускай» дигән шигырьдә ике солдатның поэтик образы, хисләре кешегә тәэсир итмичә калмый.

Әхмәт Ерикәй — лирик шагыйрь. Аның җырларында да һәм иң яхшы шигырьләрендә дә лирик мотивлар уңай сыйфатларын билгеләп торалар. Мондый шигырьләрдә һичбер нинди фальшь, салкынлык, очраклы мотивка бирелү сизелми.

Ә. Ерикәйнең кайбер шигырьләрендә салкынлык, риторик рух-фикер йөртү күренгәли, поэтик буяулары, темпераменты җитешми. Билгеле, андый шигырьләрдә гайре табигыйлек һәм ясалмалык килеп чыга, шуңа күрә андый тип әсәрләр бернинди эстетик ләззәт бирмиләр, хисне һәм фикерне уята алмыйлар. Шундый ук, эчтәлекләре уйланып җитмәгән, идея һәм кичерешләрне ачарлык буяулары, образлары табылмаган уңышсыз шигырьләр, кызганычка каршы, «Халкыма» җыентыгында да очрый. Андыйлардан: «Син айдагы кыз мәллә», «Җил», «Шәфкать кызы, бәйлә ярамны», «Сугыш, ни әйтсәң дә, сугыш инде» исемле шигырьләрне күрсәтергә мөмкин.

Ә. Ерикәй җырларында халык иҗатының яхшы йогынтысы күренә, шагыйрь фольклорны яхшы аңлап

файдалана белә. Бередә Ерикәйнең кайбер шигырьләрендә халык иҗаты образларыннан урынсызрак куллануның очравын да әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән: «Син айдагы кыз мәллә» шигырендә халык иҗатында ай, Зөһрә йолдыз, айдагы «көянтәле кыз» кебек легендалар, образлар җанлы кешеләргә мөнәсәбәттә ясалма рәвештә чагыштырылганнар.

Ә. Ерикәй бер дә чәчелми, җыр һәм лирик шигырен мөмкин булган чаклы кыска һәм җанлы итәргә тырыша. Фәлсәфи уйлану характерындарак шигырен хәтта сигез-унике юлдан да арттырмый. Моңа карап ул шигырьнең көчен, эчтәлеген һич тә киметми. «Теләк» белән «Урак урыр вакыт тагын җитте» кебек сигезәр юлдан торган шигырьләрен укып карагыз. Зур фикерне кыска шигъри юлларга сыйдыра белүдә алар үрнәк булырлык.

Ә. Ерикәй өчен лирик жанрлар характерлы булуын әйттек, эпик жанрлар исә (поэма, баллада) аның өчен характерлы түгел. Ул, нигә сәләтле икәнен белеп, үзен шулай чикли булса кирәк.

Шагыйрь «Халкыма» шигырендә үзенең бөтен иҗат көчен халкына багышлавы турында ачык әйтә:

Даннарым, дәртем, дәрманым
Минем туган халкыма.

Бигрәк тә аның җырлары бүген дә халык арасында яши.

*1946*

* * *

Югарыда әйтелгәннәргә тагын берничә белешмә өстәргә кирәктер. Әхмәт Ерикәй (1902—1967) безнең арада юк инде. Әдәбиятыбыз үсеше юлында күп еллар тырышып эшләгән, поэзиябезгә үз өлешен керткән әдипләребезне хөрмәт белән искә алырга кирәк. Ә. Ерикәйнең алтмыштан артык китабы, шулар эчендә егерме ике җыр җыентыклары басылып чыккан. Аның сүзләренә С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, Р. Яхин һ. б. музыка яздылар. Алар бүген дә халык арасында яшиләр, халык моңы булып яңгырыйлар.

*1979*